СОВЕТ
НИЖНЕУРАСПУГИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН УРЫСБАГА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**14 март 2024 ел.** Түбән Урысбага **№ 158**

Җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Урысбага авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районына тапшыру турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлешенә ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Түбән Урысбага авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен тапшырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру Түбән Урысбага авыл җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына ел саен бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла.

4 Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru һәм шулай ук Түбән Урысбага авылы, Центральная урамы, 62а йорт (җирлек хакимияте бинасы), Түбән Урысбага авылы, Үзәк урамы, 63а йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнашкан Түбән Урысбага авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Түбән Урысбага авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе Х.Х.Сибгатуллин.